КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 31 июль г.Казань № 622

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2014 ел, 21 август, 603 нче карары белән расланган Төбәк дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2014 ел, 21 август, 603 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 13 февраль, 87 нче; 2016 ел, 14 июль, 479 нчы; 2017 ел, 29 ноябрь, 923 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Төбәк дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

10 нчы пунктның 2 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«юридик затлар, индивидуаль эшмәкәрләр белән үзара хезмәттәшлектә булмыйча, тикшерүдә тоту чаралары нәтиҗәләрен анализлау буенча, вәкаләтле органга түбәндәге фактлар турында гражданнардан, шул исәптән индивидуаль эшмәкәрләрдән, юридик затлардан кергән мөрәҗәгатьләрне һәм гаризаларны, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан кергән мәгълүматны карап тикшерү яки алдан тикшерү нәтиҗәләре буенча дәүләт тикшерүендә (күзәтчелегендә) тоту органының, муниципаль тикшерүендә тоту органының вәкаләтле затының мотивлаштырылган гаризасы:»

11 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Юридик затларны, индивидуаль эшмәкәрләрне планнан тыш күчмә тикшерү вәкаләтле орган тарафыннан бу Тәртипнең 10 нчы пунктындагы 2 нче пунктчада күрсәтелгән нигезләр буенча әлеге юридик затлар, индивидуаль

эшмәкәрләр эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны буенча прокуратура органы белән килештергәннән соң үткәрелергә мөмкин.

Тикшерү (документларны, шулай ук күчмә тикшерү) үткәрү вакыты 20 эш көненнән дә артыграк була алмый.

Кече эшмәкәрлекнең бер субъектына карата план буенча күчмә тикшерүләр үткәрүнең гомуми вакыты кече предприятие өчен 1 елга 50 сәгатьтән һәм микропредприятие өчен 15 сәгатьтән артыграк була алмый.

Бу Тәртипнең 11 нче пунктындагы өченче абзацта күрсәтелгән тикшерүне үткәргәндә, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында документлар һәм (яки) мәгълүмат алу кирәк булган очракта, тикшерү үткәрү вәкаләтле орган җитәкчесе (җитәкче урынбасары) тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне гамәлгә ашыру өчен кирәкле вакытка, әмма иң күбе 10 эш көненә кадәр туктатып торылырга мөмкин. Тикшерү үткәрүне яңадан туктатып тору рөхсәт ителми.

Тикшерү үткәрүне туктатып тору вакыты гамәлдә булган чорда вәкаләтле органның әлеге тикшерүгә бәйле гамәлләре кече эшмәкәрлек субъекты территориясендә, биналарында, төзелмәләрендә, корылмаларында, бина урыннарында, башка объектларында туктатып торыла.

Катлаулы һәм (яки) озак вакытка исәпләнгән тикшерүләр, сынаулар, махсус экспертизалар һәм тикшеренүләр үткәрү ихтыяҗына бәйле булган аерым очракларда, вәкаләтле органнарның план буенча күчмә тикшерү үткәрүче вазыйфаи затларының мотивлаштырылган тәкъдимнәре нигезендә план буенча күчмә тикшерү үткәрү вакыты озайтылырга мөмкин, әмма иң күбе 20 эш көненә кадәр: кече предприятиеләргә карата – иң күбе 50 сәгатькә кадәр, микропредприятиеләргә карата – иң күбе 15 сәгатькә кадәр.

Үз эшчәнлеген Россия Федерациясенең берничә субъекты территорияләрендә гамәлгә ашыручы юридик затка карата тикшерү (документларны тикшерү дә, күчмә тикшерү дә) үткәрү вакыты юридик затның һәр филиалы, вәкиллеге, аерымланган структур бүлекчәсе буенча аерым билгеләнә, шул ук вакытта тикшерү үткәрүнең гомуми вакыты 60 эш көненнән дә артыграк була алмый.»;

13 нче пунктта:

уникенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«юридик затның, индивидуаль эшмәкәрнең тикшерүләрне исәпкә алу журналы булган очракта, әлеге журналга үткәрелгән тикшерү турында язып куела;»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«юридик затның җитәкчесен, башка вазыйфаи затын яисә вәкаләтле вәкилен, индивидуаль эшмәкәрне, аның вәкаләтле вәкилен ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынган документлар һәм (яки) мәгълүмат белән таныштырырга.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин